# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлегенең Сентяк торак пунктында

**21 нче ноябрь 2023 нче ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлегенең Сентяк торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлегенең Сентяк торак пунктында гражданнарның үзара салым салу чараларын Сентяк торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә кертергә, Бөек Ватан сугышында катнашучы һәм инвалидлардан, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Чишмәне төзекләндерү;
2. Автомобиль юлларын төзекләндерү һәм тоту;
3. Инерт материаллар сатып алу;
4. Смета документларын әзерләү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, шулай ук Олы Карауҗа авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Татарстан Республикасы адреслары буенча: Олы Карауҗа авылы, Мирная урамы, 41 йорт (советның административ бинасы), Олы Карауҗа, Күпер урамы, 23 йорт (СДК бинасы).

**Рәислек итүче гражданнар җыенында** **Р.Ф. Хөснетдинова**

**Олы Каруҗа авыл җирлеге башлыгы Совет Рәисе** **Р. Ф. Хөснетдинова**